СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

09.04.2025　　　　с. Коргуза　　　　57-292

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2, 4, 7.2 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясындагы 25, 7 өлеше, “Карагуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы, “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын бирү турында” 2025 елның 27 гыйнварындагы 16 номерлы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе карары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын һәм аның график сурәтен (кушымта) ун елга расларга.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советының 2020 елның 24 апрелендәге 65-291 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында рәсми сайтында (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Карагуҗа авылы җирлегенең торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы составында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) түбәндәге адреслар буенча: Карагуҗа авылы, Үзәк мәйдан, Егидерево авылы,Үзәк урам, 30 йорт, Патрикеево авылы, Береговая урамы, 10 йорт.

4. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы
Советы рәисе Д.В. Плохов

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 09.04. 2025 ел № 57-292 карарына

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасы

1 номерлы Карагуҗа бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-69

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Карагуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Карагуҗа авылы: Беренче Май урамы, 1-10 йорт, Садовая урамы.

2 номерлы Карагуҗа бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-62

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Карагуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Карагуҗа авылы: Үзәк урам, 1, 3, 5, 7, 9, 11 - 56 йорт.

3 номерлы Карагуҗа бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-63

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Карагуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Карагуҗа авылы, Яшьләр урамы, Үзәк урам, 2, 4, 6, 8, 10 йортлар.

4 номерлы Карагуҗа бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-69

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Карагуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Карагуҗа авылы, Яр буе урамы, 7-23 йорт, Пролетар урамы, 1-14.

5 номерлы Карагуҗа бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-65

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Карагуҗа авылы: Октябрь урамы, Первомайск урамы, 11- 28 йортлар

6 нчы Патрикеево бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-84

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Патрикеево авылы.

7 нче Егидерево бермандатлы сайлау округы

Сайлаучылар саны-65

Округка Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “Карагуҗа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше түбәндәге чикләрдә керә: Карагуҗа авылы: Боевая урамы, 1-14 йорт, Яр буе урамы, 1-6 йорт, Егидерево авылы.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 09.04.2025 ел № 57-292 карарына
2 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасының график сурәтләре